# Халкыбызның күңел бизәкләре

***Әбиебез сандыгында***
***Сакланмый нилэр генә.***
***Әйдәгез, сорыйк узеннән***
***Ачып курсәтсен безгә.***
***Каян анлап алды икән***
***Әби безнен теләкне?***
***Түрдэ торган сандыгын ул***
***Узе ачып курсәтте.***



# Баш һәм аяк киемнәре:

## Калфак

Татар хатын-кызларының рухи матурлыгын, күңел байлыгын, тегү-чигү эшләренә осталыгы, зәвыгын чагылдыручы төрки халыкларда киң таралган баш киеме.

*Энже калфак, узе ап-ак*
*Бик килешэ йөземэ.*
*Калфагымнын матурлыгын*
*Хэммэсе дә курсеннәр*
*Энже калфак кигән кыз ул*
*Татар кызы дисеннәр!*



# Түбәтәй

*Төрки халыкларда ирләрнең төп баш киеме. Түбәтәй бары тик гади тукымалардан гына тегелгән.*



Балкып тора түбәтәйлә

Энҗе бөртекләр белән

Алар монда килгән, гүя

Чын әкият иленнән.

# Читек

*Борынгы бабаларыбыз күн эшкәртүнең чын осталары булган 19нчы гасырда да татарның сафьян читекләре дан казанган.*

Бизәк төшкән итекләрне
Читекләр дип йөрткәннәр.
Аларны татар кызлары
Бәйрәмнәрдә кигәннәр…



# Бизәнү әйберләре:



## Чулпы

*Чулпының махсус ясалган алкаларына тасма киертеп, чәч толымына әнә шул тасмаларны кушып үргәннәр. Чулпы үзе тәнкәләрдән торган: ул тәнкәләрнең шомасы да, чокып бизәлгәне дә, коеп ясалганнары да булган, кайберләренә асылмалы вак тәнкәләр дә өстәлгән*

# Алкалар

*Бизәнү әйберләренең аеруча киң таралганы, мөгаен алкадыр...Татар алкалары гаҗәеп күп төрле. Әмма аеруча үзенчәлеклесе, мөгаен груша сыман яисә өйрәк формасындагы өч асылмалы алкалар. Алка асылташлар белән бизәлгән.*



# Хәситә

*Төсле тукымадан тегелә. Киңлеге 5-12 см., озынлыгы 30-40см. Тукымагаткүп төрле бизәкләр тезеп чыкканнар. Хәситәне күкрәк һәм арканы тыгыз каплап сул җилкә аша уң кул астыннан уткәргәннәр.*





# Муенса

*Борынгы бизәнү әйберләреннән. Таш гасырында аны ирләр дә, хатын-кызлар да тагып йөри. Ул бәла-казадан, яман чирләрдән саклану өчен тагылган.*





# Көнкүреш әйберләре:

## Сөлге

*Яшь кызлар үз куллары белән чигеп, сугып сөлгеләр әзерләгәннәр. Сөлгеләрнең матурлыгына карап яшь кызларның уңганлыгы, пөхтәлеге, булдыклылыгы бәяләнгән.*



# Шәл

*Шәл бәйләдем, шәл бәйләдем, шәл бәйләдем, шәл бәйләдем,*
*Шәлем түгәрәк түгел лә, шәлем түгәрәк түгел…*



# Көянтә

*Көянтәләрем алам да, чиләкләремне тагам…*




# Чиләкләр

Чиләкләрем мөлдерәмә суым жиргә туге лә…



# Сандык



*Әбиемнең сандыгы!*

*Нинди серләр саклый икән ул?*

*Гомер буе җыйган хәзинәме,*

*Әллә инде күңел бизәгеме,*

*Нинди серләр саклый икән ул?*




Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәнеңне онытма син!
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен,
Нинди уйлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.

Р. Фәйзуллин

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!





elenaranko.ucoz.ru